# Дидактик уен «Яшелчә һәм җиләк – җимешләрне танып бел»

Төзеде: 86 нчы балалар бакчасы тәрбиячесе

Галиаскарова Г.Ф.







# Уенның актуальлеге:

- Дидактик уеннарны уйнау, аларның дидактик бурычлары балаларны әйберләр, тирә-юнь күренешләрен һәм җәмәгать тормышлары турында мөстәкыйль сөйләшергә өйрәтерлек итеп төзелергә тиеш. Аларда фикерләүне һәм сөйләмне үстерү белән бердәм бәйләнештә алып барыла. Танып белү уенда аралашу, бәхәсле мәсьәләләрне чишү вакытында активлаша,үз фикерләренне дәлилләү сәләте дә үстерелә.




- Предмет белән уеннар вакытында уенчыклар һәм реаль предметлар кулланыла. Уен вакытында бала предметларны чагыштырырга, охшаш һәм аерым якларын ачыкларга өйрәнә; предметларның үзенчәлекләре: төсе, зурлыгы, формасы, сыйфаты белән таныша. Соңыннан уенның эчтәлеге катлауландыра.
- **Уен кагыйдәләрнең төп максаты:** балаларның хәрәкәтен, тәртибен оештыру. Кагыйдәләрне саклау балалардан аерым ихтияр көче, иптәшләре белән аралашу сәләтен, уңышсыз нәтиҗәгә ирешкәннән соң туган кире кичерешләрнең җиңә алуны таләп итә.



**Максат:** Балаларның яшелчә һәм җиләк-җимешләр турында белемнәрен арттыру, һәм кайда үсүләрен өйрәнү.

## Бурычлар:

- Билгеле бер үзлекләр аша предметларны төркемгә бүлергә, уенның тәртибен үтәргә омтылу.
- Яшелчә һәм җиләк-җимешләрне өйрәнүне ныгыту.
- Табигатькә сак караш тәрбияләү.
- Яшелчә һәм җиләк-җимешләрнең файдасын өйрәнү.



# Дидактик материаллар:


Макетлар: Яшелчә-җиләк-җимешләр (фетр),бакчада түтәл һәм агач макетлары.

## Уеннарның варианты:

№1.

- ”Бакчадагы яшелчә һәм җиләк-җимешләрне үз урыннарына урнаштыр”
- Уенның бурычы: Куянга яшелчә,җиләк-җимешләрнең кайда үсүен күрсәтү.


**Барышы:** Тәрбияче: Балалар, карагыз әле безгә нәрсә кунакка килгән? (куянга күрсәтә).Беләсезме балалар, куян минем колагыма әйтте, ул яшелчә, җиләк-җимешләрне аера белми икән ,ул шуңа бик кайгыра икән.Булышабызмы балалар, куянга? (әйе).Әйдәгез без аларның исемнәрең атыйбыз. Уенны болай уйныйбыз.Мин сезнең исемегезне, ә сез килеп өстәлдән модельне аласыз һәм сөйлисез: - бу кыяр,ул яшел төстә,озынча формада , тәмле ,файдалы яшелчә (җиләк-җимеш),ул безнең түтәлдә үсә (түтәлгә утырырга). Уен барлык модельләр уйнап беткәнчегә хәтле уйналына.








- №2
- “Кем җитезрәк”.
- Бурыч: Балаларның белемнәренә таянып яшелчә һәм җиләк-җимешләрне җитезлек белән хәрәкаттә күрсәтү.
- Барышы: Бер бала модельне алып күрсәтә, әгәрдә ул яшелчә булса балалар, бер аята сикерәләр , әгәрдә җиләк-җимеш булса кулларын өскә күтәрәләр һәм кул чабалар.







- №3
- “Кайсы артык”
- Бурычы: Балаларны артык предметларны табарга һәм предметларны төркемнәргә бүлергә өйрәтү.
- Барышы: Тәрбияче берәр модельне бутап агачка элә, я булмаса түтәлгә бөркетә.Бер бала кайсы предметның артык икәнен әйтергә һәм ни өчен икәнен аңлатырга тиеш.




SHINE



Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

